| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КАРМАЛКИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КАРМАЛКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

Кармалка авылы

**2018 елның 17 мае** **№11**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 2013елның 15 декабрендәге 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 172 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының 15.11.2013 № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кармалка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 17 статьяда:

2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.Җирлек бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләре;

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

социаль-икътисадый үсеш фаразы;

озак сроклы чорга бюджет фаразы (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы проекты);

дәүләт (муниципаль) программалары (дәүләт (муниципаль) программалары проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

б) түбәндәге эчтәлекле 22.1 статья өстәргә:

«22.1 Бюджет проекты белән бер үк вакытта бирелә торган документлар һәм материаллар

Бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта җирле үзидарәнең вәкиллекле органына түбәндәгеләр тапшырыла:

Россия Федерациясенең бюджет, салым һәм таможня-тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Татарстан Республикасының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

агымдагы финанс елының узган чорында тиешле территориянең социаль-икътисадый үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында тиешле территориянең социаль-икътисадый үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек территориясенең социаль-икътисадый үсеш фаразы;

тиешле территориянең берләштерелгән бюджетының чираттагы финанс елына һәм план чорына йә урта сроклы финанс планы расланган төп характеристикаларын фаразлау (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (профициты);

бюджет проектына аңлатма;

бюджетара трансфертларны бүлүнең методикалары (методикалары проектлары) һәм исәпләре;

чираттагы финанс елы (чираттагы финанс елы һәм план чорының елдан-ел) артыннан килүче елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның югары чиге;

агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

күрсәтелгән бюджет сметаларына карата вәкиллекле органнар, суд системасы органнары, тышкы муниципаль финанс контроле органы тарафыннан тәкъдим ителгән, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата финанс органы белән каршылыклар чыккан очракта тапшырыла торган күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектларын;

бюджет керемнәре чыганаклары реестрлары;

башка документлар һәм материаллар.

Дәүләт (муниципаль) программалар һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү турындагы карар белән расланган очракта, бюджет турындагы закон проектына (карар) дәүләт (муниципаль) программалар паспорты (күрсәтелгән паспортка үзгәрешләр проектлары) тапшырыла.

Бюджет турында карар проектында бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү кушымтасы булмаса, бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта бюджет турында карар проектына кушымталар составына кертелә.»

2. Әлеге карар Кармалка авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә http://leninogorsk.tatarstan.ru урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Кармалка авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе О.В.Кириллова